ГЛАВА ТАШКИЧУЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Советская, д.21А, д.Малые
Уруссу, 423959

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ТАШКИЧҮ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ
Совет урамы, 21А йорт, Кече Урыссу
авылы., 423959

Тел.:(85593) 4-23-10, факс:4-23-40, e-mail: Tash.UTz@tatar.ru

**Постановление** **Карар**
**№3** **13 октябрь 2023 ел**

2024 елга гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлегенең Ташкичү торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Советының 2019 елның 17 июлендәге 9 санлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Ташкичү авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 14, 81 маддәләре, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Советының 2019 елның 25 октябрендәге 17 санлы карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында»гы нигезләмәнең 4 пунктындагы 4.4 пунктчасы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге башлыгы,

КАРАР ИТТЕ:

1. 2023 елның 26 октябрендә 18.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлегенә керүче Ташкичү торак пунктында Татарстан Республикасы Ютазы районы, Ташкичү авылы, Чишмә урамы, 28А йорт, авыл мәдәният йорты бинасында 2024 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенә керүче Ташкичү торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлегенә керүче Ташкичү торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш, 2024 елда 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертүгә

һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә риза булырсызмы:

-Ташкичү торак пунктында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материаллар, җиһазлар, транспорт хезмәтләре сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү).

«ӘЙЕ» «ЮК».

3. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын әзерләүне һәм уздыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Ташкичү авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгару һәм Татарстан Республикасының Ютазы муниципаль районы сайтында «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм Порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә кабул ителгән көннән алып 5 көн эчендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Ташкичү авыл җирлеге башлыгы Р.К.Вәлиев